# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ
**(IV чакырылыш)**

**КАРАР**

IV чакырылыш чираттан тыш утырышы

11 март, 2022 ел №16 Урыссу ш.т.п.

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә, Иске Каразирек, Ташкичү, Урыссу авыл җирлекләре генераль планнарын әзерләү зарурлыгы булмау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясындагы 6 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә, Иске Каразирек, Ташкичү, Урыссу авыл җирлекләре территорияләрендә җирлекләр территориясеннән гамәлдәге файдалануны үзгәртү күздә тотылмавы белән бәйле, җирлекләр территорияләрен социаль-икътисадый үстерүнең расланган стратегиясе булмавы, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең территориаль планлаштыру документлары белән федераль әһәмияттәге объектларны, төбәк әһәмиятендәге объектларны, җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру каралмаган булуы сәбәпле, Татарстан Республикасы Ютазы районы Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә, Иске Каразирек, Ташкичү, Урыссу авыл җирлекләре генераль планнарын әзерләү зарурлыгы булмавын танырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының экология һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы башлыгы
вазыйфаларын башкаручы -
Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Советы Рәисе З.В. Ильясов